«БАЛ» ДИП БАЛЛАНМЫЙ

Гали Маннановның бал кортлары нәрсәсе белән үзенчәлекле?

> 2

ТУГРЫЛЫК ҮРНӘГЕ

Россия Герое Дамир Исламовка Казан танк училищесында бюст куелды

> 3

КИЕМЕҢӘ КАРАП...

Китапны укысынnar өчен, язучының нинди булуы да әһәмиятле

> 3

КҮРЕП СӨЕНСЕННӘР

Казанда XVIII мөселман кинофестивале узды. Нәтиҗәләре нинди?

> 4

ВАТАНЫМ ТАТАРСТАН

1918 елның 12 мартыннан бирле чыга | ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ГОМУМТАТАР ГАЗЕТАСЫ | № 133 (28906) | Сишәмбе | 13 сентябрь | 2022 ел

Газета 1968 елда Хезмәт Кызыл Байрагы ордены белән бүләкләнде

www.vatantat.ru /vatanimtatarstan /t.me/vatantat

4604609 000131

Көзге ярминкә

Узган шимбә республикада көзге ярминкәләр башланды. Алар 24 декабрьгә кадәр дәвам итәчәк. Татарстанның Авыл хуҗалыгы министрлыгының матбугат үзәге мәгълүматларына караганда, узган ел көзге ярминкәләрдә 2 миллиард сумлык продукция сатылган. Ярминкәдән кем файда күрә? Алучымы, сатучымы?Ниләр саталар? Бәяләр ничек? «ВТ» журналисты шимбә көнне ярминкә мәйданнарын урап чыкты.

Илдар Мөхәммәтҗанов

АВЫЛ ШӘҺӘРГӘ КИЛДЕ

Ул көнне биредә бөтенләй башка мохит. Берничә сәгатькә шәһәргә авыл күчеп торган төсле. Авыл халкы да шәһәрнекеләрнең күңелен төрле яктан күрергә тырыша. Җырлап торучылар да, гармун уйнап биетүчеләр дә бар. Хәтта сатып алучыларны чәй һәм коймак белән дә сыйлап җибәрәләр. Казанның агросәнәгать паркында инде иртәнге сигездә товарлар бетеп, кайбер машиналар кайтырга әзерләнә иде.

– Быел кыш бәяләрнең күтәрелүе безне болай да җиргә якынайткан иде инде. Бакчаларны шуңа зурайттык бит. Үзегез беләсез, кыш көне кибетләрдә кәбестәнең килограммы 65–70 сумга җитте. Ә бездә бик арзан. Халык шуңа да капчыклап ала, – ди Арча районыннан килгән Диләрә Сафина.

Ул кишер белән чөгендер саткан. Кышка дип әзерләнгән тозлы кыяр, помидор, салатларының бер литрлы банкасын 50 сумнан алып та бетергәннәр.

Ә менә «Кукмара сөте» сату ноктасында эш кызу. Халык чиратка тезелгән. Бәяләре кибетнекеннән югарырак та әле. Әмма сыйфаты яхшы дип, бер ияләнгән кеше күтеп кенә тора икән. Казанда яшәүче Нурзия Хәбибуллина ярминкәгә нәкъ менә Кукмара сөте алырга килгән.

– Аларның эремчеге дә тәмле, каймагы да. Узган ел атна саен шулардан гына алып йөрдем. Сатучысы да таный хәзер. Әллә нинди әйбер кушылганны ашыйсы килми бит. Яхшыга ияләнгәч тә начар, – ди ул, шаяртып.

Кукмара дигәннән, инде алар орлык суган да сата башлаган. Березняк җирлегеннән килүчеләр, аны сортларга бүлеп, килосын 150–200 сумга сата. Итләрне дә күп итеп алып килгәннәр. «Нырты» совхозында яшәүче фермер Илшат Хәмизов күп еллар маллар тота икән. Ярминкәгә кызы белән бергә килгәннәр.

– Казан ярминкәләре бик ошый безгә. Ичмасам, акча кайта. Районда да сатабыз. Әмма анда итне аз алалар. Вакыт әрәмгә уза, сату бармый. Монда без берничә сәгать эчендә шактый ит сатабыз, акчасы да әйбәт керә. Ярминкәгә җиде баш тана суеп алып килдек. Инде соңгысын башладык, – ди ул. – Гел бездән генә алучы кешеләр бар. Алар килгәнебезне көтеп тора. Ярминкәгә барырга берәү дә мәҗбүр итми. Киресенчә, фермерларга дәүләт ярдәм кулы суза. Монда килер өчен ягулык бирәләр, сату урыны бушлай. Эшләгән акчаң үзеңә. Рәхмәттән башка сүз юк.

Икенче рәт тулысынча Мамадыш фермерларыныкы иде. Алар ярминкәгә ныклап әзерләнгән. Сату рәтләрен бизәргә дә өлгергәннәр. Райондагы бөтен җитештерелгән товар бирегә күчкән, диярсең. Мамадыш сыры да, балыгы да, казылыгы да, лимонады да, ипие дә бар. Яшелчәләрне дә күп итеп алып килгән булганнар.

Дегетле җирлегендә урнашкан колония-поселение хезмәткәрләре алып килгән бәрәңге, кишер, чөгендерне иртәнге сигезгә сатып та бетергәннәр иде инде. «Халык бәясенә кызыгадыр инде. Капчыклап алу отышлы да бит. Болай тиз сатылып бетәр димәгән идек», – ди Васил Дәүләтшин.

Буа районы уңганнары янында да булдык. Алар шикәр комының килограммын 60 сумнан саткан. Без килгәндә, аннан да җиләр искән иде инде.

– Әлегә узган елгы шикәр комын сатабыз. Беренче көн булгач, күп тә алып килмәгән идек. Әмма халык сыпыртып алды. Икенче атнага күбрәк алып киләсе булыр, – ди сатучы Гөлия ханым.

Сатып алучыларның кәефе ничек соң? Безгә очраганнары арасында күңелсезләнгәне булмады. Бары тик аратирә бәя төшертеп йөрүчеләр күзгә чалынды. Аларны да аңлап була. Килолап сатылучы товарны капчыклап алып киткәч, бәяне төшертәсе килә инде ул. Әнә үзен Заһир дип таныштырган ир-ат бөтен җирдә 25 сум торган кишерне сеткасы белән 20дән алды да китте.

Биредә кәрҗиннәре тулган, тәгәрмәчле сумкалары авырлыкка түзә алмыйча ватылган кешеләр дә күп иде. Глушко урамында яшәүче Нурия Гайнуллина ни генә алмаган. Сумкасында суган да, кишер дә, май да, сөт тә, ит тә, кабак та, бал да бар… «Әлегә бәрәңгене алмый торам. Иртәрәк дип уйлыйм. Хәзер гел килеп торачаклар бит инде, алырмын әле», – ди ул.

Нурия апа белән сөйләшкәндә, яныбыздан матур итеп киенеп, кызын култыклап барган әбигә күзем төште. Ирексездән, ниләр алдыгыз, дигән булам. Ә ул исә, яшьлегемне сагынып, эзләп чыктым, ди. Тәтеш районының Әтрәч авылында яшәгән, олыгайгач, кызы янына күчкән Рәмзия Ибраһимова авыл халкының тырышлыгын яхшы белә. «Төн йокламыйча монда килеп, товар сатучыларга рәхмәт дими ни дисең. Файдам тисен, дидем әле, карарга дип чыккан идем, сумкам тулды инде», – диде ул.

Гөлгенә ШИҺАПОВА

САН

Казанда көзге ярминкәнең беренчесе 15 җирдә узган. Анда Татарстанның 22 районыннан килеп сату иткәннәр. Казанга товар тулы 620 машина килгән. 350 тонна бәрәңге, 27 тонна кәбестә, 40 тонна шикәр комы, 138 мең данә йомырка һ.б. алып килгәннәр. Республика буенча ярминкәдә 77 миллион сумлык товар сатылган.

Бәяләр *(сумнарда)*

Бәрәңге (кг)	18
Кәбестә (кг)	13
Шикәр комы (кг)	60
Бал (3 литры)	1500
Агызып ала торган сөт (литры)	40
Пакеттагы сөт (литры)	55
Кишер (кг)	25
Чөгендер (кг)	25
Кабак (кг)	20
Суган (кг)	25
Сыер ите (кг)	460–480
Атланмай (кг)	420
Сыр (кг)	380
Он (кг)	30
Йомырка (дистәсе)	80–100

Еракка барасы юк

Казанның 4 метро станциясе – «Җиңү проспекты», «Кәҗә Бистәсе», «Яшьлек» һәм «Авиатөзелеш» станцияләре янында вакцинация пунктлары ачылды. Алар һәр көн саен, шул исәптән ял һәм бәйрәм көннәрендә, төшке ашка гына туктап (көндезге 1дән 2гә кадәр), иртәнге 8дән кичке 7гә кадәр эшләячәк. Биредә грипптан – «Совигрипп», коронавирустан – «Спутник V» вакцинасы белән берьюлы ике прививка ясатырга мөмкин. Вакцинацияне борынга тамызу ысулы белән генә дә узарга була. Моннан тыш, халыкка уңайлы булсын өчен, Казанның 7 нче хастаханәсендә төнге сәгатьләрдә эшләүче вакцинация пункты да ачылган.

Сүз уңаеннан, узган тәүлектә Татарстанда COVID-19 йоктыруның 893 (алдагы көндә – 828) яңа очрагы ачыкланган. Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов узган шимбәдә, коронавирус йоктыручылар саны артуны искәртеп, республикада яшәүчеләргә битлек киеп йөрергә һәм прививка ясатырга киңәш итте.

Хәл итү юлларын эзләргә

Хәзерге вакытта ил буенча 234 меңгә якын хезмәткәр мәҗбүри ялга җибәрелгән яки тулы булмаган эш көненә җәлеп ителгән. Бу хакта Россия Президенты Владимир Путин белдерде. «Бу ел башындагыга караганда ике тапкыр диярлек күбрәк. Әлбәттә, ил буенча зур сан түгел. Әмма билгеле бер тармаклар, предприятие һәм торак пунктлар җитди кыенлыклар алдында калды. Шуңа күрә Хөкүмәт җирле проблемаларны игътибар үзәгенә алырга һәм алардан чыгу юлларын табарга тиеш», – диде Президент. Шул ук вакытта, дәүләт башлыгы билгеләп үткәнчә, хезмәт базарындагы хәлләр тотрыклы. Эшсезлек, моңарчы күрелмәгәнчә, бик аз дәрәҗәдә.

Сентябрь башында Татарстанстат хәбәр иткәнчә, быел икенче кварталда республикада 6,5 мең хезмәткәр эш бирүченең гаебе белән, шулай ук башка сәбәпләр белән эшсез утырырга мәҗбүр булган. Бу – хезмәткәрләрнең гомуми санының 0,7 проценты.

Яшь эшмәкәргә ярдәм

Татарстанда эшмәкәрләргә грантлар бирү тәртибенә үзгәреш кертелгән. Хәзер аларга социаль эшмәкәрләр генә түгел, бәлки 25 яшькә кадәрге бизнесменнар да дәгъва кыла алачак. Премьер-министр Алексей Песошин имзалаган карарда әйтелгәнчә, акча шул исәптән бизнес-проектларны гамәлгә ашыруга бәйле чыгымнар өчен бүлеп бирелә. Грант алуга гариза тапшырганда, эшмәкәр предприятиенең устав капиталының кимендә 50 процентына ия булырга тиеш.

Ярдәм күләме проект бәясенең 25–50 процентын тәшкил итә. Шул ук вакытта, карарда билгеләп үтелгәнчә, эшмәкәр проектка үз акчасының кимендә 25 процентын җәлеп иткән очракта гына субсидия алырга мөмкин.

kzn.ru

Бер елмаю да җитә

Казан Россиянең иң тыныч шәһәрләре исемлегендә 8 нче урынга чыккан. Түбән Новгород, Санкт-Петербург һәм Сочи исемлектә беренче өч урынны алган. «Работа.ru» һәм «СберЗдоровье» хезмәтләре, халык арасында сораштыру үткәреп, шундый нәтиҗә чыгарган. Респондентларның 42 проценты Түбән Новгородны яклап тавыш биргән. 37 проценты Санкт-Петербургны иң тыныч шәһәр дип санауларын әйткән. 35 проценты Сочины сайлаган. Иң тыныч 10 шәһәр исәбенә шулай ук Ярославль, Калининград, Вологда, Мәскәү, Казан, Владимир һәм Краснодар кергән.

Сораштыруда катнашучыларның 59 проценты фикеренчә, тыныч тормышка хас төп билгеләр – тормышның салмак кына агышы һәм буш вакытка ия булу. 49 проценты искәрткәнчә, елмаючан, ачык йөзле кешеләр шәһәргә тынычлык иңдерә. 35 проценты билгеләп үткәнчә, урамнары чиста, юлларында машиналар аз булган шәһәрне, тыныч шәһәр, дип атарга мөмкин. Шулай ук халык саны аз, ә шәһәрнең кечкенә булуы, аз катлы йортларның өстенлек итүе дә тынычлык билгеләре булып санала.

Сайлау – 2022

Нәтиҗәләр билгеле

Тыныч, төгәл, көндәшле һәм хәвефсез. Татарстан Үзәк сайлау комиссиясендә Бердәм тавыш бирү көненә йомгак ясадылар. Республика (Россиянең башка төбәкләре кебек үк) иртәнге 7дән кичке 8гә кадәр Дәүләт Советына депутатлар һәм җирле үзидарә органнарына вәкилләр сайлады.

Татарстан Үзәк сайлау комиссиясе рәисе Андрей Кондратьев сүзләренчә, республикада тавыш бирү тыныч барган. Кандидатлар арасындагы көндәшлек тә көчле иде дип бәялиләр. Ул билгеләп үткәнчә, республикада тавыш бирү барышына йогынты ясаучы җитди кагыйдә бозулар ачыкланмаган. Гомумән, барысы да Татарстанга хас рухта узган.

Искәртеп үтик: 11 сентябрьдә республиканың 39 районында 181 сайлау округы буенча тавыш бирү үткәрелде. Җирле үзидарә органнарына 180 депутат сайланды.

– 667 кандидат теркәлгән иде, – дип, сайлау нәтиҗәләре белән таныштырды Андрей Кондратьев. – Уртача алганда, бер мандатка 3,7 кеше дигән сүз. 11 кандидат үз теләкләре белән сайлау кампаниясендә катнашудан баш тартты.

Шулай ук Ибраһимов һәм Пионер бер мандатлы сайлау округлары буенча Дәүләт Советына өстәмә депутат сайлау оештырылды. Ике урынга 12 кеше дәгъва иткән иде. Аның нәтиҗәләре болайрак:

> 7 нче Ибраһимов бер мандатлы сайлау округында, 57,30 процент тавыш җыеп, Рима Мөхәммәдшина депутат булып сайланды. Казанның азык-төлек һәм социаль туклану департаменты генераль директоры өчен 5406 кеше үз тавышын биргән. Ул бу сайлауда үз-үзен тәкъдим итүче булгарак катнашты.
> 14 нче Пионерлар бер мандатлы сайлау округында «Бердәм Россия» партиясеннән тәкъдим ителгән Дмитрий Анисимов, 64,39 процент тавыш җыеп, алдынгылыкка чыкты. «Стратегик инициативалар үзәге» директоры өчен 10857 кеше тавыш биргән.

Быелгы сайлауда 123118 кеше тавыш бирә ала иде. Бу – республиканың сайлау хокукына ия булган халкының 4 проценты дигән сүз. Сүз уңаеннан, Ибраһимов округы буенча тавыш бирергә килүчеләр күрсәткече – 20,7, ә Пионер округы буенча 21,7 процентны тәшкил иткән.

Сүзгә-сүз

Владимир ПУТИН, Россия Президенты:

Россия тышкы басымга, кайбер илләрнең финанс-технологик агрессиясенә бирешми. Без мәшгульлекне һәм эш урыннарын саклауга, гражданнарга һәм, беренче чиратта, балалы гаиләләргә, пенсионерларга ярдәм күрсәтүгә юнәлдерелгән чаралар кулландык. Нәтиҗәдә икътисадның кискен хәлсезләнүенә юл куймау, инфляцияне тотрыкландыру мөмкин булды.

(Икътисади мәсьәләләр буенча утырыштан)

ТАТАРСТАНДА – ТОРАК ТӨЗЕЛЕШЕ

Республикада быел 2,5 млн кв. метр торак төзелгән. Бу – еллык планның 91 проценты.

ШӘХСИ ЙОРТЛАР – 12959 йорт – 104%



СОЦИАЛЬ ИПОТЕКА – 106 мең кв. метр – 70%

КОММЕРЦИЯЛЕ ТӨЗЕЛЕШ – 644 мең кв. метр – 70%



Рәшит ФӘТХРАХМАНОВ

Дөньяда

ПХЕНЬЯННЫҢ АТОМ КҮСӘГЕ

Үткән атнаның дөньякүләм вакыйгасы, әлбәттә, Бөекбритания тарихындагы иң дәвамлы идарәнең королева Елизавета II вафаты белән төгәлләнүе булды. 70 ел патшалык иткән шәхеснең үлемен күп кенә аналитиклар, Җир шары масштабында глобаль эпоханың төгәлләнүен символлаштыра, дип бәяләделәр. Англиядә король идарәсе бик чикләнгән һәм минималь күләмдә генә. Монархиянең икътисадка да, сәясәткә дә, социаль тормышка да тәэсир итәрлек мөмкинлекләре юк диярлек. Әмма шуңа да карамастан, король гаиләсе ил күләмендә генә түгел, дөнья масштабында да ниндидер серле йогынтыга ия. Елизавета II белән хушлашу зур ритуал төсен алды һәм ул 19 сентябрьгә кадәр дәвам итәчәк.

Никадәр генә тарихи шәхес булмасын, бер кешенең үлеме дөнья вакыйгаларын бүтән сукмакка күчерә алмый. Юл алыштыру, бүтән сукмак эзләү күптән планетакүләм юнәлешкә әйләнде инде. Чынлап та, кешелек дөньясы элекке лидерлар белән генә түгел, элекке тормышы белән дә хушлаша. Җир шарының бөтен төбәкләрендә сәяси система айкала да чайкала. Моңа кадәр яшәп килгән тотрыклылык югала. Конфликтлар үсә. Без атнадан атнага зур бәрелешләргә китерергә ихтимал булган яңа каршылыкларның шаһиты булабыз. Болар турында язасы да, искә аласы да килми килүен, әмма нишлисең, тормышыбыз шундый.

Әнкара белән Афина яңадан сугыш чигендә торалар. Традицион рәвештә этле-мәчеле яшәгән бу ике дәүләт, бер үк хәрби блок әгъзалары булсалар да, үзара тыныша алмыйлар. Төрек лидеры үткән атнада тагын грекларга: «Әгәр хәзерге курсны дәвам итсәгез, кыйбат түләрсез!» – дип янады. Эгей диңгезендәге утраулар тирәсендәге бәхәс ике илгә ызгыш алмасы буларак хезмәт итә. Төрекләр үз хәрби самолетларының очышына греклар С-300 ЗРК системасының радиолокацион станцияләрен эшләтеп комачаулыйлар дип баралар һәм, провокацияләрне туктатмасалар, күршеләренә хәрби һөҗүм белән яныйлар. Бу янаулар тормышка ашырылса, бәрелеш төбәк конфликты булудан гына туктап, эш зурга китәргә ихтимал. Әрдоган көнбатышлыларның Россиягә керткән санкцияләрен дә кискен тәнкыйтьли. Хәтта Украинага озаткан коралларын да «искереп беткән металлолом» дип бәяли.

Әйе, әйе, Россиянең көньяк-көнбатыш чиге дөньякүләм тартыш мәйданына әверелү потенциалына ия. Ул төбәктә атом-төш шартлавы була күрмәсен дип, барыбыз да куркып торабыз. Кыйтганың башка ягында да массакүләм үтереш коралы мәйданга чыгам дип яный. Төньяк Корея рәсми рәвештә атом-төш коралына ия дәүләт статусын алды һәм билгеле бер шартларда куркыныч коралны куллану белән яный. Буш янау гына түгел бу. Соңгы вакытларда Пхеньян үзенең ракета арсеналын бик нык камилләштерде. Анда очыш траекториясен үзгәртергә сәләтле каты ягулыкта эшли торган заманча ракеталар саны артты. Боларның стартын күреп алу бик кыен, бәреп төшерү дә катлаулы. Ким Чен Ын алдагы биш елда компактлы оператив-тактик атом-төш бомбаларын ясау боерыкны да куйды, диләр. Бу үзе генә дә төбәктә ашкынып кораллануның яңа спирален бөтерергә сәләтле. Көньяк Корея һәм японнар Пхеньянга каршы җавап системаларын үстерергә тиеш булып чыгалар.

Россиядә

ТҮШӘМ КУЙСАЛАР, АРЗАНГАРАК САТАРБЫЗ

Эпоха белән бәхилләшү глобаль капитализмның «ирекле базар» дигән инструментының эшләми башлавында да чагыла. Әле кайчан гына чикләрнең ачык булуы, бәяләрнең чикләнмәве, товарларның муллыгы белән мактанган Көнбатыш державалар, үз принципларыннан баш тартып, яңа кагыйдәләр кертергә, бәяләрне чикләргә, товар хәрәкәтен тышауларга азапланалар. Моның шаукымы, бумеранг булып, чикләү кертүченең үз башына да суга, хәтта катырак та эләгә әле. Әмма ниндидер бер яшерен көч лидерларны сәяси шахмат тактасында үзе теләгәнчә йөртә, аек акылга буйсынмый торган адымнар ясата. Без, Россиядә яшәүчеләр, андый «ат йөрешләре»нең авырлыгын тоймый кала алмыйбыз. Әйтик, Россия банкларын халыкара түләүләр системасыннан өзү, валюта резервларын «туңдыру» акчалы россиялеләргә ничегрәк тәэсир итте? Алар, ашкынып, үзләренең валюта запасларын ышанычлырак урынга күчереп калырга керештеләр. Үзәк банк мәгълүматларына караганда, февральдән алып сентябрьгә кадәр хәлле ватандашлар чит илләргә 1,019 триллион сумга тиң валюта чыгарганнар. Акча Казахстанга, Берләшкән Гарәп Әмирлекләренә, Төркиягә качкан. Бездә булсалар, фантик ролен генә үтиләр, чикнең теге ягында затлы күчемсез милеккә әверелә доллар һәм еврolar. Белгечләр ел ахырына кадәр тагын шуның кадәр валюта читкә чыгарылыр дип фаразлый.

Көнбатышлылар белән «углерод сугышлары» да без бик үк теләмәгән нәтиҗәләргә китерә яисә китерергә ихтимал. «Төньяк агым»ның газ кранын ябу Көнбатыш базарын тулысынча югалту белән яный. Мәскәүдә «бер ел бөтенләй газ сатмасак та, чыдар җаебыз бар» дип саныйлар санавын, әмма газны эчке базарда гына куллану аның рентабельлелегенә тискәре йогынты ясаячак, диләр күп кенә аналитиклар. Моңарчы эчке базардагы бәяләрнең түбәнлеген тышкы базарның югары бәяләре белән каплап киләләр иде. Көнбатышлылар, теләмәсәләр дә, безнең эчке базардагы бәяләрне субсидияләделәр. Хәзер ул рычаг юкка чыгып бара. «Газпром» үз илендәге кулланучыларга бәяне күтәрми кала алырмы – әлегә билгесез. Күтәрсә, бик югары күтәрергә туры киләчәк.

Нефтькә «түшәм бәяләр» сәясәте дә кая кадәр алып барып чыгар, шулай ук мәгълүм түгел. Россия «дус» илләрне Көнбатышка буйсынмаска өнди. Һиндстанның нефть һәм газ министры Хардип Сингх Пури Россия нефтенә бәйле сорауга: «Без бер кварталга Европа бер кичтә сатып алган кадәр генә Россия нефте сатып алабыз», – дип җавап бирде. Күрәбез: Һиндстан белән аркадашлык безне бик әллә ни коткармаячак. Һиндстан газетасы Business Standard яңа гына G7 илләре куйган түшәм бәяне Нью-Дели кире какса, Россиянең Һиндстанга «кара алтын»ны тагын да түбәнрәк бәягә сатарга әзер булуын язып чыкты. Әгәр бу дөрес булса, «Балта биреп, шөшле алдым, алдаладым татарны» кебек килеп чыга бит инде.

ЯРДӘМ ВАКЫТЫНДА КИЛӘЧӘК

tatarstan.ru

Татарстанга Россиянең гадәттән тыш хәлләр министры Александр Куренков килде. Федераль министр Президент Рөстәм Миңнеханов белән Казанда һәм Чаллыда коткаручыларны техника белән тәэмин итү турында сөйләште.

Иң элек алар Россия Гадәттән тыш хәлләр министрлыгының Кече суднолар буенча дәүләт инспекциясе (ГИМС) командалары арасында су-мотор ярышлары буенча илкүләм чемпионатны ачу тантанасында катнашты. Ярышлар 12–15 сентябрь көннәрендә Кабан күле буендагы Ишкәкле спорт төрләре үзәгендә уза. Чемпионатта федераль округлардан җыелган 8 команда чыгыш ясый. ГИМС инспекторлары ярышта кече суднолар белән идарә итү һәм катлаулы шартларда кешеләрне коткару осталыгын күрсәтә. Александр Куренков билгеләп үткәнчә, чемпионатта катнашучылар – көн саен кешеләрнең иминлеген тәэмин итүче чын коткаручылар. «Чемпионатны уздыру безнең хезмәткәрләргә тәҗрибә алмашу һәм үз һөнәри осталыкларын камилләштерү өчен бик яхшы мөмкинлек бирә», – диде министр. «Безнең республика өчен әлеге чемпионатны кабул итү – зур мәртәбә. Без катнашучылар өчен иң уңайлы шартлар тудырырга тырыштык. Ярышлар иң югары дәрәҗәдә узар, дип ышанам», – диде Татарстан Президенты.

Аннары Рөстәм Миңнеханов белән Александр Куренков Россия Гадәттән тыш хәлләр министрлыгының Татарстан буенча баш идарәсе бүлекчәләренә 11 янгын сүндерү һәм коткару техникасы тапшырды. Министрлык һәм Татарстан Президенты ярдәме белән республикадагы янгын сүндерү-коткару бүлекләренә соңгы ике елда 24 берәмлек техника тапшырылды һәм тагын 27 автомобильгә капиталь ремонт ясалды.

Башкаладагы 3 нче янгыннан коткару бүлегендә һәм кризис шартларында идарә итү үзәгендә булганнан соң, Рөстәм Миңнеханов белән Александр Куренков Казан вертолет заводына юл тоттылар. Россия гадәттән тыш хәлләр министрына биредә яңартылган Ми-8МТВ-1 вертолетын күрсәттеләр. Беренче 5 очкычны нәкъ менә әлеге министрлыкка тапшырачаклар. Ми-8МТВ-1 МЧСның махсус заказы буенча заманча таләпләрне исәпкә алып эшләнгән. Гомумән алганда, Казан вертолет заводы Россия Гадәттән тыш хәлләр министрлыгына Ми-8 төрендәге 40тан артык очкыч тапшырган.

Горбунов исемендәге Казан авиация заводында Рөстәм Миңнеханов белән Александр Куренков очыш-сынау станциясендә булды, Ту-214 очкычын җитештерү эшләре белән танышты, алга таба хезмәттәшлек турында фикер алыштылар.

Казаннан соң Татарстан Президенты белән Россия гадәттән тыш хәлләр министры Чаллыга да сәфәр кылды. КамАЗга барып, соңгы яңалыкларны күргәннән соң, киңәшмәдә коткаручыларны техника белән тәэмин итү турында сөйләште.

Дәүләт Советында

ЭЛЕКТР ТРАНСПОРТЫНА – ИҢ ЗУР ӨМЕТ

Шәһәр электр транспортын капиталь төзекләндерү программасы булдырырга, билетсыз йөрүчеләргә штраф күләмен йөз тапкыр арттырып, 300 сумнан 3600 сумга җиткерергә. «Метроэлектротранс»та Дәүләт Советының Торак сәясәте һәм инфраструктураны үстерү комитеты белән комитет каршындагы Экспертлар советы уртак күчмә утырышында шундый тәкъдимнәр булды.

Утырышта Татарстанда пассажирлар йөртүне оештыру өлкәсендәге закон үтәлешен мониторинглау буенча зур эшкә йомгак ясадылар. Парламент комитеты әгъзалары ел ярым эчендә зур шәһәрләрдә җәмәгать транспортына бәйле проблемаларның ничек хәл ителүен өйрәнгән. Шәһәрнең җир өсте электр транспортында һәм автомобиль транспортында пассажирлар йөртүне оештыру турында республика законына үзгәрешләр кертү мониторингның төп йомгакларыннан берсенә әйләнгән. Мониторингка соңгы нәтиҗә парламент президиумының якындагы утырышында ясалачак.

Комитет утырышы алдыннан депутатлар «Казметрострой» генераль директоры Марат Рәхимов белән «Ломжа урамы» һәм «Сахаров урамы» станцияләрендә метроның икенче линиясен төзүнең барышы белән таныштылар. Хәзерге вакытта станцияләр ике тоннель белән тоташтырылган, барлыгы 2220 метр озынлыкта җир асты юлы салынган. Тоннель казу комплекслары аена 200 метр араны казып үтә. Икенче линиянең беренче өлешен (4 станция) төзү якынча 41 миллиард сумга төшәчәк.

Марат Рәхимов әйтүенчә, беренче участокны 2027 елда файдалануга тапшыру күздә тотыла. Метро төзүчеләр ел азагына кадәр акча белән тәэмин ителгән. Хәзерге вакытта төп төзелеш-монтаж эшләре алып барыла. Якын араларда инженерлык челтәрләрен сузу, тоннельләр һәм станцияләрне бизәү-әзерләү кебек зур чыгымлы эшләр башланып китәчәк.

Комитет утырышында электр транспортын үстерүгә аерым тукталдылар. «Метроэлектротранс» генераль директоры Айдар Абдулхаков билгеләп үткәнчә, хәзерге вакытта Казанда 9 трамвай, 10 троллейбус маршруты, бер метро линиясе эшли. Электр транспортын карап тоту, аңа хезмәт күрсәтү, бигрәк тә вагоннарны һәм инженерлык челтәрләрен ремонтлау зур чыгымнар сорый. Шуңа күрә ул шәһәр электр транспорты инфраструктурасын капиталь төзекләндерү программасын эшләүнең максатка ярашлы буласын искәртте.

Сүз уңаеннан, «Метроэлектротранс» генераль директоры билетсыз йөрүчеләргә штраф күләмен 100 тапкыр арттырып, 3,6 мең сумга җиткерергә тәкъдим итте. Моннан тыш ул билетсыз баручыларга штраф салу өчен вәкаләтле махсус муниципаль орган булдырырга кирәклеген әйтте.

УРТАК МИЛЛИ ЧИШМӘБЕЗ

Казахстанның Семей шәһәрендә I Иртыш буе Халыкара Сабан туе гөрләде. Бәйрәмдә Татарстан Дәүләт Советы Рәисе Фәрит Мөхәммәтшин да катнашты.

Бәйрәм алдыннан Фәрит Мөхәммәтшин Сабан туе узган Абай өлкәсенең хакиме Нурлан Уранхаев белән очрашты һәм Казахстан Республикасы Президенты Касыйм-Жомарт Токаевка Татарстанга карата яхшы мөнәсәбәте өчен рәхмәт белдерде.

– Югары дәрәҗәдә ирешелгән килешүләр Россия – Казахстан арасында булган дустанә мөнәсәбәтләр нигезендәге зур эшләргә әверелер дип ышанам, – диде ул.

Нурлан Уранхаев исә Сабан туеның Казахстан гына түгел, Иртыш буенда урнашкан Россия шәһәрләрендә гомер итүче татарларны да берләштерүен искәртте.

– Бөтен Казахстандагы кебек үк, Абай өлкәсендә бик күп төрле милләтләр яши. Ничәмә-ничә гасырлар дәвамында бу җирлекләрдә гомер кичерүче татарлар белән безне туганлык җепләре бәйли. Алга таба безнең элемтәләр тагын да ныгыр дип ышанам, – диде ул.

tatarstan.ru

Дәүләт Советы Рәисе белән килгән Татарстан делегациясе шәһәрдәге Татар сәнгать мәктәбендә дә кунак булды. Әлеге очрашуның ядкәре итеп, Фәрит Мөхәммәтшин мәктәпкә тальян бүләк итте.

Шуннан соң Фәрит Мөхәммәтшин белән Нурлан Уранхаев Габдулла Тукай һәм күренекле казах шагыйре Абай Кунанбаев һәйкәлләренә чәчәкләр салдылар. Кунаклар 2013 елда Татарстанның Беренче Президенты Минтимер Шәймиев катнашында нигез салынган аллеяда агачлар утырттылар.

– Гасырлар аша безнең көннәргә килеп җиткән Сабан туе – кадерле милли байлыгыбыз, – диде Фәрит Мөхәммәтшин, бәйрәм кунакларын сәламләп. – Тарихи Ватаннарыннан еракта яшәүче милләттәшләребезнең йөрәкләрен җылыта торган татар мәдәнияте чишмәсе. Әлеге бәйрәм рухи якынлыкны тоярга, милләтара тынычлыкны һәм татулыкны ныгытырга ярдәм итә. Бүгенге бәйрәмдә кунакларның күп булуы бик сөендерә. Кунаксыз Сабан туе – бәйрәм түгел инде ул!

Казахстанда яшәүче татарлар төбәкнең социаль-икътисади үсешендә дә зур роль уйный. Нурлан Уранхаев шулай дип белдерде.

– Сабантуй инде күптән бөтен халыкларның уртак бәйрәменә әверелде. Безнең өлкә төзелгәнгә өч ай булды. Әлеге утрауга бердәмлегебезне һәм җаваплылыгыбызны, тарихка, мәдәнияткә һәм традицияләргә тугрылыгыбызны күрсәтү өчен җыелдык, – диде ул, Сабан туе кунакларын бәйрәм белән котлап.

Бәйрәм Бейбитшилик утравында узды һәм барлыгы 10 меңләп кешене җыйды. Сабан туе иҗади чыгышлар, күргәзмәләр һәм милли уеннар белән үрелеп барды. Сүз уңаеннан, бәйрәмне оештыру өчен Татарстаннан Актаныш районы җаваплы иде. Традицияләргә тугры калып, бәйрәмнең баш батырын да ачыкладылар. Аңа Татарстан Президентының махсус бүләге – квадроцикл тапшырылды.

ТӘМЛЕ БАЛ

Эш кешесе

Кортлар кермәсен арага. Актаныш районының Чиялек авылында яшәүче умартачы Гали Маннанов күршеләре белән ничек дус яшисен белә. Чакмый торган кортлар асрый ул, шуңа күрә аңа дәгъва белдерүчеләр дә юк. Германия, Польшадан кайтартылган бал кортлары да әлеге җирлекне үз иткән. Тәгәрмәчле умарталыгы булган Гали Маннанов белән тәмле бал алу серләре турында сөйләштек.

Кортларның – үз көе

Умартачылык эшендә 32 ел узса да, бал кортларын һаман да өйрәнеп бетереп булмый әле, ди ул. Һава торышына карап, алар холкын үзгәртеп тора.

– Узган ел җәй бертөрле булды. Быел яңгырлар булгач, күп умартачыларныкы күч аерды. Бу вакытта аларга эш җитми башлый. Шуңа күрә үсемлекләр чәчәк ата башлагач, башка урын эзләп, агач башларына саралар, – дип сөйли Гали абый. – 2010 елгы корылыкта бал уңышы белән сөендермәде. Быел яңгыры да, җылысы да булгач, балны узган елга караганда яхшырак алдык. Яңгыр явып, гел җил исеп торса да начар, үсемлекләр нектар бүлеп чыгармый. Көннәр эссе булса исә, ягъни 29–32 градуста, киресенчә, нектар куера башлый. Бу да файдага түгел. Нечкәлекләре күп инде аның.

Армиядән кайткач, 1990 нчы елларда авылдагы бер бабайдан бер күч корт алып, балачактагы хыялын тормышка ашырган ул. Бераздан кызыксынуын белеп, колхоз умарталыгына эшкә чакырганнар. Тик ике елдан кыскартуга эләккән. Шуннан соң үз хуҗалыгында асрый башлаган. Берничә оядан бүген аларның саны 200гә җиткән. Абыйсы Филүс белән бергәләп эшлиләр.

«Безгә тимиләр»

Маннановлар да башта рус токымлы кортлар асраганнар. Татарстанда, Башкортстан, Пермь краенда гадәттә шундый кортларга өстенлек бирәләр.

– Алар бик усал. Соңгы балны алгач та, берничә көн бәйләнеп йөриләр иде. Ишеткәнем бар: 3–4 умарта асраган кеше дә күршеләре белән ачуланышып, эшләр хәтта судка кадәр барып җитә. Күч аерып чыгып та китәләр. Хәзер безнең умарталыкта – «Бакфаст» токымнары. Күршеләр белән дә ачуланышмыйбыз, үзебезгә дә тимиләр, үтеп йөрүчеләрне дә чакканнары юк. Алар янында битлек кимичә, футболканы салып йөрим. Дуслар да, ничек чакмыйлар, дип аптырый, – дип сөйли Гали әфәнде.

Кайбер умартачылар Гали абый белән, син дөрес эшләмисең, дип бәхәсләшеп тә ала. Янәсе, рус кортлары безнең җирлеккә күптән ияләшкән, ә чит илнекеләр алай түгел.

– Умартачылардан: «Балыгызны суыртып бетермәдегезме әле?» – дип сорыйм. Юк, әле алып бетермәдек, күршеләргә кунаклар кайтты бит, бала-чагалары да бар, алар киткәнне көтәбез, диләр. Алар киткәнне көтеп, яңгырга китсә? Күршеләрен чагып, җәфалап бетерәчәген аңлый ул, шуңа күрә кунаклар киткәнне көтә. Алар киткәч, икенче күршегә кунаклар кайтса? Әйтик, мин 100 умартаның балын кайчан алып бетерим? Минем хәзер кортларым тыныч, тыңлаучан. Әгәр безнең яктагы кортлар ул кадәр шәп булса, аларга чит илләрдә ихтыяҗ булыр иде.

Тәгәрмәчле умарта

Моннан ун ел элек Гали абый 60лап умартасын Мөслим басуларына илтә башлаган. Анда кортларын юкәлеккә куя ул. Читкә йөртүнең үз кыенлыклары бар. Умарталарны төяргә кирәк, иртүк чыгып китәргә… Тик еракка йөрү табышны икеләтә арттыра. Юкә иртәрәк, июнь ахырында ата, бу вакыт ике атнага сузыла. Аны суыртып кайтканда, башка басуларга да кергәлиләр. Менә шулай керем дә арта. Хатыны Лилия ханым: «Еракка арып-талып йөрмәгез инде», – дисә дә, тәгәрмәчле умарта гел сәфәргә чакырып тора. Тәмле бал кайта бит. Бал төрле булгач, халыкка да сайлап алу мөмкинлеге бар. Балың тәмле, дию – умартачыга иң зур бәя. Өч литрлы банкадагы чәчәк балын 1500 сумга сата. Юкәнеке 300 сумга кыйммәтрәк.

Сәрия МИФТАХОВА

Илдар Мөхәммәтҗанов

ГАЛИ МАННАНОВ КИҢӘШЛӘРЕ

Бал утырырга тиешме?

Глюкоза күп булган саен, бал тизрәк утыра. Көнбагыш, рапста, горчицада күп була ул. Кеше шундый балны ала да, шыгырдап катты, кашык та тыгып булмый, дип зарлана. Шикәр комы кушканнар, ди. Юк, бу алай түгел. Әлбәттә, умартачы да, сатканда: «Бу рапс балы, тиз утыра», – дип әйтергә тиеш. Дөрестән дә, ике атнадан ката инде ул, без аны берничек тә үзгәртә алмыйбыз. Мәсәлән, донникныкы озаграк утыра. Ә менә яртылаш кына утырса, бу – бал җитешмәгән дигән сүз. Бал утырырга тиеш.

Чын бал нинди була?

- Чын бал тамакны әчеттерергә тиеш, дигән сүз һәрвакытта да дөреслеккә туры килми. Бөтен балның да тәме ачык чагылмаска мөмкин. Кайберсенең йомшаграк була, кайберсенеке тамакны бераздан әчеттерә башлый.
- Балда вак куыклар күренергә тиеш. Начар балда ул булмый. Банканы фонарь белән яктыртып карый аласыз.
- Энәне балга батырып карыйсың. Аның очыннан 1–2 тамчы тама да өченчесе очына җыела, тик тамып төшми.

3 литр банкага күпме бал сыя?

Юкә балы – 4300–4500 г; донник балы – 4200 г; чәчәк балы – 4400 г.

ДАН ҺӘМ СОКЛАНУ

БАШКАЛАДА РОССИЯ ГЕРОЕ ДАМИР ИСЛАМОВ ИСЕМЕН МӘҢГЕЛӘШТЕРДЕЛӘР

Казан танк училищесында Россия Герое Дамир Исламовның бюстын ачтылар. Тантана Танкистлар көне алдыннан узды. Бюст ачудан тыш, училищеда беренче курс студентларының Ватанга тугрылык өчен ант бирү тантанасы да үтте.

Яшь егетләр өчен үрнәк – күз алдында. Училище шәкертенең батырлыгын телгә алмый калмыйлар биредә.

– Без аның батырлыгын һәм башка геройларның истәлеген хөрмәт итәргә бурычлы. Алар үзләренең хәрби бурычын лаеклы үтәде, Ватаныбыз мәнфәгатьләрен яклады, – ди училище җитәкчесе, генерал-майор Кирилл Кулаков.

Аның сүзләренчә, хәрби училищеның батырлар белән мактанырлыгы бар. 76 Советлар Союзы Герое, 74 Социалистик Хезмәт Герое, 4 Дан ордены тулы кавалеры, 25 Россия Герое, 2 Изге Георгий ордены кавалеры кайчандыр бу уку йортында белем алган. Аларның күпчелеге училищеның Дан аллеясында урын алган инде. «Әле бу гына да түгел: махсус хәрби операциядә катнашкан 10 шәкертебез Россия Герое исемен йөртә. Без алар белән горурланабыз», – диде генерал-майор.

Дамир Исламов бюстын ясауда Казанның иң яхшы сынчылары катнашкан. Таш һәйкәлне егеткә мөмкин кадәр охшаш итеп ясарга тырышканнар. Килеп чыккан да төсле.

– Бюстка карап, янымда Дамир басып торган кебек тоям. Мин ниләр кичергәнне сүз белән генә аңлатырлык түгел, – диде Дамир Исламовның туганы Диләрә. – Безнең гаилә Дамир белән горурлана. Аның үлеме турында без хәрби хезмәттәшләре аша белдек. Соңгы минутка кадәр ышанмадык. Моны хәзер искә алган саен авыр. Ярдәм итеп, терәк булган кешеләргә рәхмәт әйтәбез.

Чарада катнашкан Татарстан Президенты Аппараты җитәкчесе Әсгать Сәфәров та мәрхүмнең күркәм сыйфатларын телгә алды.

– Күпмилләтле Россия армиясе составында махсус хәрби операция барышында республикабызда туып-үскән кешеләр катнаша. Илгә хезмәт итү юлын сайлагач, алар барысы да хәрби бурычларын лаеклы үти, еш кына үз гомерләре бәрабәренә дә, – дип сөйләде Әсгать Сәфәров. – Бүген без Россия Герое, якташыбыз Дамир Исламовның бюстын ачтык. Өлкән лейтенант Дамир Исламов үзенең кыска гомерен лаеклы һәм гадел итеп үткәрде. Аны белгән һәркем егетнең тыйнаклыгын, намуслы булуын телгә ала.

Чара тәмамлангач, курсантлар тантаналы марш белән узды һәм ант кабул итте.

«Татар-информ»

Дамир Исламов – Лениногорск егете. Ул анда 6 нчы мәктәптә белем алган, соңрак Казан танк училищесын тәмамлаган. Ростов өлкәсендә хәрби хезмәттә була. 25 яшьлек егетнең гомере Украинадагы махсус операция барышында 7 мартта өзелә. Аның экипажы, дошман белән бәрелешкә кереп, биш танктан дүртесен юк итә. Алга таба һөҗүмгә барганда, Дамирның танкы дошман снаряды тиеп шартлый. Һәлак булган экипаж әгъзаларының барысына да Россия Герое исеме бирелә. Араларында Татарстаннан тагын бер егет – Дамир Гыйлемханов та бар.

Мин кулыма китап алам

ЯЗУЧЫ БРЕНДЫ

Китап нинди булырга тиеш? Аны нәрсә сата? Без бу мәсьәләгә җитәрлек дәрәҗәдә кагылып уздык инде. Кабатланып тормыйм. Әйе, аның тышлыгы матур, эчтәлеге яхшы, исеме кызыктыргыч һ.б. булырга тиеш. Ләкин боларның барысын да икенчел яссылыкка күчерүче бер феномен бар, ул – язучының исеме. Исемнең ничек яңгыравы да кирәк инде, шуңа күрә кайберәүләр ата-инәләре кушкан исемнән баш тартып, яңгырашлырак псевдоним юнәтү ягын хәстәрли. Ләкин әлегә сүз – авторның шәхесе, укучының аны ничек итеп, кем дип күз алдына бастыруы турында.

Нилектән шулай киләдер инде ул, татар укучысы өчен язучының әсәрләре генә түгел, ә кем, нинди шәхес булуы да мөһим. Хәтта шәхеснең зурлыгы беренчелрәк тә бугай әле. Башка халыкларда бу бик үк мөһим түгел шикелле, бәлки, мин генә белеп бетермимдер. Менә Әнгам Атнабаевны гади кешеләр аңларлык дәрәҗәдә язганы өчен генә түгел, ә катлаулы чорларда да үз телен үзгәртмичә, татарча язып, татарча сөйләшеп, әйтер сүзен дөреслекнең күзенә карап әйткәне өчен яраттылар. Ул үзенең башбирмәс рухы, баш китәрлек фикерләрен дә юморга төреп бирә белүе белән бүтән каләмдәшләреннән кискен аерылып торды.

Чордаш әдипләребездән Ркаил Зәйдулланы мисалга китереп карыйк. Ул да – гадәти язучы гына түгел, фикер иясе, төрле сәяси, милли вакыйгаларга карата үз карашын ачыктан-ачык белдереп баручы зур шәхес. Кайчагында фикерләре бик уйланылган, кайчагында артык кискен була. Ләкин ул боргаланмый, дөресен әйтә, һич югында үзе инанган дөреслекне җиткерә. Һәм аннан шуны көтәләр дә. Ниндидер вакыйгалар уңаеннан үзе башлап сүз кузгатмаса, журналистлар килеп фикерен сорый. Укучыларның күз алдында ул хөр фикерле, ирек сөючән, сүз халык-милләт мәнфәгатьләре турында барганда яклап чыга алырлык кыю шәхес булып яши. Аны менә шуңа яраталар, хәтта бер генә шигырен укымаган кеше дә: «О, ул бит – зур шагыйрь!» – дип соклана. Шәхеснең үзенчәлеге аның әсәрләрендә дә чагылыш таба. Һәм аны бүтән каләмдәшләреннән кискен аерып куя. Язучының менә шундыйрак үзенчәлеген бүген заманча итеп «автор бренды» дип йөртәләр. Үзенчәлек яки бренд төрлечә була. Ркаилның фикерен, яклау сүзен көтсәләр, мәхәббәт турында егылып ятып укырлык китаплар яза торган популяр язучы Зифа Кадыйровадан берни дә көтмиләр, аннан бары тик елатырлык әсәрләр генә көтәләр. Бу җәһәттән Зифаның бренды иң отышлысы, җайлысы. Сәяси яки милли мәсьәләләрдә нәрсәдер әйтсә, бу бераз гайре табигый булып ишетелер иде. Һәм ул әйтми дә. Чагыштыру өчен монысы… Әгәр Ркаил Зәйдулла дәшми калса яки Зифа Кадыйрова ниндидер сүз әйтсә, сәер тоелыр иде. Менә шундый үзенчәлек инде. Бренд.

Автор бренды үз укучысына якын булырга тиеш. Ркаил Зәйдулла иҗатын аң-белеме дә, зәвыгы да югары дәрәҗәдәге (яки үзләрен шулай бәяләгән) кешеләр үз итә. Болар үзләре дә җәмәгать эшендә катнаша, төрле вазыйфалар алып бара һәм автордан да әсәрләр язу гына түгел, ә җәмәгать эшлеклесе булуны көтә. Кайчагында таләп тә итәләр. Ә Зифа Кадыйрова китаплары хәреф таныган һәр кешегә аңлашыла. Шуңа күрә аны савымчылар да, сатучылар да, хуҗабикәләр дә, нечкә күңелле ирләр дә яратып укый. Мондый укучылар җәмәгатьчелек алдына басып чыгыш ясый, теге я бу вакыйга уңаеннан фикер белдерә торган кавем түгел һәм авторга таләпләре дә гади генә. Кыскача гына әйтсәк, автор укучылары өчен «үз кеше» булырга тиеш. Хәтта күпмедер дәрәҗәдә аларның уй-фикерләрен чагылдыручы, ә вакыты белән юнәлеш бирүче, әйдәүче, юатучы, уйландыручы, сабак бирүче, канат куючы. Язучы шәхесе укучыга никадәр якынрак, аңа шул дәрәҗәдә ныграк тартылалар, яраталар, хәтта кайбер җитешсезлекләрен дә гафу итәләр.

Язучыны укучылар өчен шәхес буларак ачуның иң отышлы юлы – әдәби очрашулар. Әле күпләр синең китабыңны укымаган, кайберләре хәтта барлыгыңны да, кемлегеңне дә белми, я вакыт үтерергә, я иптәшләренә ияреп кенә килгәннәр. Син үзең, иҗатың турында сөйлисең, сорауларга җавап бирәсең, кыскарак әсәрләреңне яки романыңның берәр өзеген укып күрсәтәсең. Кыскасы, укучыларың яки китабыңны укырга мөмкин булган кешеләр белән аралашасың. Әгәр ихлас булып, аларның йөрәгендә үз ояңны үрә аласың икән – җиңдем дип уйларга мөмкин. Алар синең китапларыңны алачак, иҗатыңны күзәтеп барачак.

Популяр язучыларның кайсын гына алсаң да, аларның бер уртак ягын табасың – барысы да очрашулар үткәрә. Мин тагын үзем яраткан Атнабайны мисалга китерәм инде, Башкортстанда ул булмаган бер генә авыл да юк иде. Үзен күреп белгәч, шигырьләре дә якын булып тоела инде, һәр төбәкнең һәрбер кешесе аның турында сүз барганда: «Ә-ә, мин бит аны беләм, ул килде безгә. Сәхнәдән чыгыш ясаганда хәтта миңа озаграк та карап торды әле», – дип әйтә ала.

Әдәбият сөючеләр белән очрашулар вакытында авторның китапларын да күп алалар. Үзем белән булган очракны алданрак әйтеп үттем инде. Хәзер бөтенләй башка кеше, бүтән милләт язучысы турында сөйлисем килә. Тайфур Сәгыйтов. Башкорт язучысы ул, сирәгрәк яза, әллә нинди премияләре дә юк бугай, артык данлыклылардан да исәпләнми. Мин белгәндә шулай иде инде, аралаша торган кешем түгел, бәлки, хәзер бүтән төрлерәктер. Менә шул язучының «Дусның хатыны» дигән романы бар. Әйбәт әсәр. Лев Толстой колачы да, Достоевский тирәнлеге дә юк анда, ләкин бик мавыктыргыч, тирән кичерешле, ихлас. Авторның үзен дә бик чибәр егет дип булмый, кечкенә буйлы, йөз-биткә дә артык әллә ни түгел. Менә шул кеше белән очрашу оештырдылар. Теплоходта бу. Темадан читкә китү кебек тоелмаса, мин бер киңәш бирергә телим: укучылар белән очрашуларны мотлак теплоходта яки корабльдә оештырырга кирәк, чөнки тирә-якта су, беркем дә чыгып качалмый. Мин ул чорда яшь һәм бик популяр идем. Бу очрашуга да барырлык башка урыным булмаган өчен генә кердем. Һәм ул миңа бик зур сабак булды. Тайфур агай шундый ихлас, үзеннән дә әйбәтрәк булырга тырышмый, кыланмый, хәтта иң мәкерле кебек сорауларга да сабыйларча беркатлылык белән җавап бирә. Аның беркатлылыгы, ихласлыгы теге мәкерне эретеп юкка чыгара. Кыскасы, ул мине сокландырды. Әсир итте. Һәм әлеге әсәрне «Агыйдел» журналында басылган чагында ук укуыма карамастан, аның китабын мин сатып алдым. Махсус күзәтеп барганым юк, әмма Тайфур Сәгыйтовның берәр яңа китабына юлыксам, мин аны мотлак алачакмын, укыячакмын. Яшьлегемдә калган шул бердәнбер очрашу тәэсире бу. Менә нинди кодрәткә ия ул язучының үзе белән очрашу!

Моны барысы да беләдер инде. Һәрхәлдә, чит илләрдә аны бик еш һәм уңышлы кулланалар. Ниндидер язучының китабы чыга икән, әйтик, Стивен Кингныкы, Американың бик күп шәһәрләре буйлап аның белән очрашулар үткәрәләр. Кинг үзе дә маладис, коточкыч жанрындагы әсәрләр язуына карамастан, ул очрашулар вакытында юмористка әверелә, залны рәхәтләндереп көлдерә, авызына гына каратып тота. Кумирларының өлкән яшьтә дә дәртле һәм шат икәненә сөенгән укучылар аның китапларын чират торып ала, автографлар куйдыртырга тырыша. Барысы да гади генә кебек…

Менә мондый алымнарны безгә дә кулланырга кирәктер. Әллә ни зур чыгымнар да таләп итми бит инде ул. Китапка кызыксыну уятучы иң зур көч ул – язучының исеме. Шәхесе. Заманча кыландырып әйтсәк, язучы бренды. Бренд дигән сүзне мин бик яратмыйм. Һәр язучы ШӘХЕС булырга тиеш.

Марат КӘБИРОВ

Авыл хәлләре

Күңел салу кирәк

Урып-җыю «менә башланам, менә башланам» дип торган көннәр иде. Балтач районының Нөнәгәр авылыннан күптәнге танышым Наил абый Салихов шалтырата. 91 яшьтә булса да, ул әле дә бөтен нәрсә белән кызыксына, барысыннан хәбәрдар.

– Сеңлем, Фердинанд тагын сөендерде бит әле, – дип башлады ул бу юлы сүзен. Фердинанд дигәне – ул яшәгән җирлектәге хуҗалык җитәкчесе Фердинанд Хәйруллин. – Басу-кырларда йөртеп кайтты, фермаларда булдык, яңа бакча-мәктәп комплексын, ремонттан соң ачылган мәдәният йортын карадык. Мине генә түгел, райондагы унлап элекке хуҗалык рәисләрен кунакка чакырган булып чыкты. Кая гына барсак та, эшләрен күреп сокландык. Бүген көн саен утыз тонна сөт саталар икән. Бу – безнең чор рәисләре ышана торган сан да түгел. Бөтен җирдә тәртип, басуларында бөтен төрле уңыш та күкрәп үскән, бер бөртек чүп үлән күрмәссең, барлык ферма яннары шау чәчәктә. Яңа мегафермасында хәтта үзләрендә эшләүчеләр өчен тавык асрыйлар, яшелчә үстерәләр, җиләк-җимеш агачлары утыртканнар. Гаҗәп инде менә! Башка бер генә урында да элекке җитәкчене Фердинанд кебек зурламыйлар. Минем бит инде рәислектән киткәнгә дә утыз ел…

Фердинанд һәм аның командасы ирешкән уңышлар турында без берничә тапкыр яздык инде. Яңалыклардан курыкмыйлар. Бераз бармый торсаң, бу хуҗалыкта әллә никадәр үзгәреш була.

– Тавык та асрый башладыгызмыни? – дип шалтыратам Фердинандка.

– Күптәнге фикер иде инде ул. Ниһаять, быел җитешеп, йомырка сала торган 50 тавык, 2 әтәч алып җибәрдек. Аларга матур гына кетәклек салып куйдык. Йомыркалары үзебезнең ашханә өчен булыр дидек.

–Яшелчә дә үстерәсез икән…

– Теплицада кыяр-помидор үстерә башладык. Анысын да бу язда беренче тапкыр гына утырттык, үзебезнең ашханә өчен дип инде…

– Мегаферма янына җиләк-җимеш агачлары да утырткансыз, диләр…

– Барысы да шул ферма тирәсендә инде аның. 138 төп алмагач-груша агачларын Киров питомнигыннан бер ел гарантия белән килеп утыртып киттеләр. Үсмәгәннәрен бер ел эчендә кабат утырталар дигән сүз…

Ферма дигәндә, күпләр тездән саз ера торган, үтеп-чыгып булмый торган урыннарны күз алдына китерәдер. Бардыр, әлегә кадәр андыйлары да бардыр. Тик Фердинанд кебек тәртип, чисталык ярата торган урында исә, каралтылары да җепкә тезгән кебек, идеаль тәртиптә урнашкан, ферма ишегаллары да шау чәчәктә булыр. Әйләнә-тирәсендә тавык-чебешкә дә, теплицага, җиләк-җимешкә дә урын табылыр. Мегаферма берничә елдан яшеллек уртасында калачак, димәк. «Әле анда урын иркен бит, хыялда тагын берәр фикер юкмы соң?» – дигән сүземә җитәкче көлеп кенә куйды. Димәк, бар әле. Анысын алга таба күрербез.

«Җитен үстереп карарга булдык»

Шулкадәр кызык (яки кызганыч) заманда яшибез. Күз каршында гына булган әйберләрне, әллә кайдан «кычкырып» торган үзгәлек-яңалыкларны да күрми-белми калабыз. Баксаң, безнең каршы тау өстендәге басуга быел «Татарстан» хуҗалыгы җитен чәчкән булган икән. Зәп-зәңгәр чәчәк аткан җитен басуына игътибар да итмәүчеләр бер мин генә түгел булып чыкты. Яныннан үтеп китеп тә күрмәгәнмен, басуга күтәрелеп тә карамаганмын, диючеләр дә булды.

…Авылга кергәндә, тау өсте уч төбендә кебек күренә. Җәяү булсаң да, машинада булсаң да күз ташлау гына кирәк. Кызганычка, берничә тапкыр үтәргә туры килсә дә, күрмәгәнмен. Алай да бер машинада кайтканда: «Рәфкать, тау өстендә нинди зәңгәр томан соң ул?» – дип сорадым элекке күрше егетеннән.

– Томан түгел ул, Гөлсинә апай, җитен чәчәк аткан, – ди.

Шул көнне үк басуга менәм, фотога төшерәм, дигән ният барып чыкмады. Мин җитешеп менгәндә инде әлеге сихри матурлык югалган, җитеннең нәфис зәңгәр чәчәкләре санаулы гына калган иде.

– Быел җитен үстереп карарга булдык шул, – диде, бу хакта сорашкач, хуҗалыкның баш агрономы Фирдүс Хәкимов. – Районда әлегә без генә. Акрынлап рапстан китеп булмасмы икән дигән идек. Бик рентабельле культура булса да, аңа игътибар шулкадәр күп кирәк. Корткычлар бик ярата үзен. Елга кимендә биш мәртәбә химикатлар белән эшкәртергә, әледән-әле карап торырга кирәк. Атна-ун көн эчендә бөтен хезмәтең юкка чыгарга, корткычлар ашап бетерергә мөмкин. Химикатлар белән эшкәрткән саен умартачылар турында да онытмаска кирәк. Ә җитенне бер тапкыр чүп үләннәргә каршы эшкәрттек тә башка бер нәрсә дә сиптермәдек. Аны республикада үстерүче хуҗалыклар бар инде. Без орлыгын Алтай өлкәсеннән кайтарттык. Быел 74 гектарга игеп карадык. Рапсны да үстерәбез әле, анысын 160 гектарда чәчтек. Җитенне үстерүнең бер авырлыгын-мәшәкатен дә күрмәдек. Уңышы әйбәт булды, уңышлы итеп сатып та булса…

Безнең буын – җитен күргән буын түгел. Өлкәнрәкләр җитен йолкырга йөрүләрен, саламы бераз йомшарсын өчен ат, машина юлына салуларын, соңрак авылга җитен талкый торган җайланма кайтуын, аннан сүс ясауларын хәтерли. «Аны колхоз сата иде. Авыл кешесе үзе дә өй-мунча, бурадан абзарлар салганда сүсне кулланды. Ул чакта өй саен җитен орлыгы була иде, күзгә чүп керсә дә, шуны салалар, мал-туарның ашказаны тыгылса, эшләмәсә дә, шуны кайнатып эчерәләр иде», – дип искә ала алар.

Гөлсинә ХӘБИБУЛЛИНА

КОТЛЫЙБЫЗ!

Татарстан Республикасының социаль-икътисадый үсешенә зур өлеш кертүе, актив җәмәгать һәм хәйрия эшчәнлеге өчен «АК БАРС» акционерлык коммерция банкы (гавами акционерлык җәмгыяте) идарәсе рәисе **Гәрәев** Зөфәр Фәнил улы **«Дуслык» ордены** белән бүләкләнде.

***

Районның социаль-икътисадый үсешенә мөһим өлеш кертүе һәм күпьеллык нәтиҗәле хезмәте өчен Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы башлыгы **Хаҗипов** Нәҗип Нәкыйп улы **«Татарстан Республикасы алдындагы казанышлар өчен» ордены медале** белән бүләкләнде.

***

Татарстан Республикасының социаль-икътисадый потенциалын ныгытуга зур өлеш кертүләре һәм күпьеллык нәтиҗәле хезмәтләре өчен «Универсиада авылы» Татарстан Республикасы дәүләт автоном учреждениесенең сервисны оештыру бүлеге әйдәүче белгече **Абдуллин** Илгиз Абдулла улы, Казан шәһәренең «Водоканал» муниципаль унитар предприятиесе директоры **Егоров** Андрей Юрьевич, Татарстан Республикасы Спас муниципаль районы башлыгы **Мөхәммәтов** Фәргать Вагыйзь улы, **Севастьянов** Александр Петрович, «Универсиада авылы» Татарстан Республикасы дәүләт автоном учреждениесенең баш бухгалтеры **Соловьев** Альберт Евгеньевич, хезмәт ветераны **Шәмсетдинов** Ринат Мөхәммәдәмин улы **«Татарстан Автономияле Совет Социалистик Республикасы төзелүгә 100 ел» медале** белән бүләкләнде.

***

«Республика туберкулезны дәвалау клиник диспансеры» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесенең 2 номерлы диспансер бүлекчәсе (балалар) мөдире – табиб-фтизиатры **Биккенина** Гөлсәнә Камил кызына, «Республика туберкулезны дәвалау клиник диспансеры» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесе баш табибының медицина часте буенча урынбасары **Газизуллина** Наилә Кәбир кызына, «Республика туберкулезны дәвалау клиник диспансеры» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесенең «Чаллы туберкулезны дәвалау диспансеры» филиалы баш табибының медицина часте буенча урынбасары **Нелюбина** Елена Тимофеевнага, «Республика туберкулезны дәвалау клиник диспансеры» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесенең 4 номерлы диспансер бүлекчәсе (балалар) мөдире **Теплова** Татьяна Петровнага **«Татарстан Республикасының атказанган табибы»** дигән мактаулы исем бирелде.

***

Россия Федерациясе Граждан оборонасы эшләре, гадәттән тыш хәлләр һәм табигать бәла-казаларының нәтиҗәләрен бетерү министрлыгының Татарстан Республикасы буенча Баш идарәсе су объектларында кешеләрнең иминлеген тәэмин итү бүлеге башлыгы **Гаязова** Регина Әдип кызына, Россия Федерациясе Граждан оборонасы эшләре, гадәттән тыш хәлләр һәм табигать бәла-казаларының нәтиҗәләрен бетерү министрлыгының Татарстан Республикасы буенча Баш идарәсе Дәүләт янгынга каршы көрәшү хезмәте янгынга каршы көрәшү федераль хезмәтенең 7 янгын сүндерү-коткару отряды 6 янгын сүндерү-коткару часте башлыгы, эчке хезмәт подполковнигы **Лукоянов** Евгений Владиславовичка **«Татарстан Республикасының атказанган коткаручысы»** дигән мактаулы исем бирелде.

ЯЛ ИТӘРГӘ ВАКЫТ ЮК

Иртә торсаң, ит пешә. Аксубай районының Иске Кыязлы авылында яшәүче эшмәкәр, фермер Әлфирә Шакированың тормыш девизы бу. Күп еллар буе хуҗалык тотучы Әлфирә ханым ике ел элек авылда кулланучылар кооперативы ачкан. Ит эшләнмәләре җитештерү предприятиесендә бүген эш гөрли.

– Фермерлык белән күптән шөгыльләнәм. 2019 елны 5 миллион сумлык грант оттык. Бу акчага бина, җиһазлар сатып алып, кулланучылар кооперативы төзедек. Авыл хуҗалыгы министрлыгы да бик ярдәм итте безгә. Мондый ышаныч һәм хуплау булганда, тагын да яхшырак эшлисе килә, – ди Әлфирә Шакирова.

Кооперативта ит эшкәртәләр, сөт җитештерәләр, ярымфабрикатлар ясыйлар. Әлфирә Шакирова әйтүенчә, иттән җитештерелгән ярымфабрикатларны халык бик теләп сатып ала.

– Пилмән, мантый, кәтлит, тутырмалар, тулма (голубцы) ясыйбыз. Пилмәнгә аеруча сорау зур. Тиз генә пешереп алырга җайлы бит. Тутырманы да яратып алалар. Мантыйның килосын – 400, пилмәнне – 200, тутырманы 600 сумнан сатабыз, – ди фермер.

Ит кытлыгы юк, җитә, ди Әлфирә ханым.

– Итне пайчылардан алабыз. Аларда булмаса, үзебезнекен суябыз. Суганнарны да складка җыеп куйдык. Ул да эшкәртүгә кирә. Фаршларга, кәтлиткә кулланабыз. Суганны үзем дә күпләп үстерәм. Быел уңыш бик әйбәт булды, шөкер. Йомыркаларны пайчылардан, кыш көннәре кибетләрдән алып куябыз, – ди фермер.

Кооперативта барлыгы өч кеше эшли. Эш көне иртәнге җидедә башлана һәм кичке дүрткә кадәр дәвам итә.

– Кечкенә генә коллективым белән алга таба да уңышлы эшләрбез, дип уйлыйм. Эш сөючән һәм җаваплы хезмәткәрләр булганда, башкача була да алмый, – ди фермер, елмаеп.

Шакировларның 35 баш сыерлары бар. Сөтне, итне малайлары Казанга алып китеп сата. Нурлатта ике сату урыны бар. Махсус суыткычлы машина алганнар, шуның белән йөртәләр икән. Җитештерелгән продукцияне кибетләргә дә илтәләр. Әлфирә апа әйтүенчә, игенчелек, терлекчелеккә караганда, эшкәртү эше үзенә күбрәк игътибар сорый.

– Безнең өчен бу яңарак тармак булгач, ияләнеп бетеп булмый әле. Иң табышлысы – фермерлык. Кибетнең хәзер файдасы юк. Авылда кибет булмаганга гына төзеп куйдык аны. Анда бит акча сала барасың, югала бара. Ә терлекне суеп саткан акча югалмый, күзгә күренә, – ди ул.

Үз хуҗалыгыңны тоту – тынгысыз һәм мәшәкатьле хезмәт. Тик Шакировларны бу куркытмый, аларның барысы да җайга салынган. Әлфирә апаның тормыш иптәше Рәис, уллары Илүс һәм Айзат – төп ярдәмчеләре.

– Гаиләбез белән бергәләп эшлибез. Ял итәргә вакытыбыз юк безнең. Җәен дә, кышын да мәш килеп эшләп йөрибез. Иң мөһиме – сәламәтлек булсын, – ди Әлфирә Шакирова.

Илдар Мөхәммәтҗанов

Ләйсән САФИНА

Кризис нигъмәте

«Кризис» сүзе кытай телендә ике иероглиф белән языла, ди. Шуның берсе «төшенкелек», икенчесе «мөмкинлек» дигәнне аңлата. Димәк, кризис ул нәрсәнеңдер түбәнгә төшүе һәм шул ук вакытта нәрсәнеңдер үсүе. Физика фәне дә безне «кайдадыр нәрсәдер югалса, димәк, кайдадыр нәрсәдер барлыкка килә» дигәнрәк законнары белән өметләндерә. Әгәр боларны эшмәкәрлеккә күчерсәк, шуны аңлыйбыз: кризиста бизнеснең кайбер төрләре сүрелә, ә кайберләре үсә. Менә кризис заманына кулай шөгыльләрнең кайберләре.

ПРОКАТ

Кризис вакытында кеше зур әйбер алмаска тырыша, акчасын экономияли, шуңа күрә прокат, арендага бәйле эшләр уңышка ирешергә мөмкин. Бу төрле өлкәләргә карый. Әйтик, туйга күлмәк биреп тору, эш коралын арендалау, велосипед, спорт җиһазларын прокатка бирү. Хәтта фатирны да арендага бирү очраклары арта, ди риелторлар, чөнки кризиста фатир сатып алулар кими.

РЕМОНТ

Әйткәнебезчә, кеше яңа әйбер алмаска тырыша, шуңа күрә искесен ремонтлый. Сәгать, телефон, суыткыч, кер юу машинасы дисеңме… Яңаны алыр идең дә, ә ник әле искесен генә ремонтламаска? Диван, карават, кәнәфи тышлауларны да шушында кертә алабыз. Бу да – үзенә күрә ремонт бит.

ЧИСТАРТУ

Ремонт белән янәшә тагын бер өлкә бар: чистарту. Химчистка хезмәте, мәсәлән. Кризиста костюм-чалбар, пальто, ярактан кроссовканы химчисткага бирүләр арта. Идәндәге палас, ковролиннарны да бик шәп юалар хәзер. Үзләре алып китә, үзләре китереп бирә. Яңа паласны кризис беткәч алырсыз.

ЭЧКЕ ТУРИЗМ

Төркиягә бару хәзер ничә сум? Караганыгыз бармы? Карамагыз да, егылып китәрсез! Мондый шартларда эчке туризм киң җәелә. Монда экскурсовод хезмәте дә, хостеллар да, сувенир сатулар, күңел ачу, аш-су – барысы да кирә. Соңгы елларда глэмпинг дигән формат популярлашты. Табигать кочагында затлы кунакханәләр төзеп, ял итүчеләр өчен уңайлы шартлар тудыралар.

УКЫТУ

Һәр төрле бизнес-укулар, тренинглар, мастер-класслар көндәлек тормышта да бик күп, кризиста алар аеруча актуальләшә. Ник дигәндә, «төшенкелек һәм мөмкинлек» чорында адәм баласы тормыш алып барыр өчен яңа юллар эзли, яңа һөнәрләр үзләштерә, кайвакыт эшләгән җиреннән китә (яки җибәрәләр). Мондый шартларда яңа һөнәр, яңа компетенцияләр бирүче остазларның тәҗрибәсе аеруча кыйммәт.

Кыскасы, як-ягыгызга карап яшәгез, төшенкелеккә бирелмәгез, мөмкинлекләр эзләгез. «Кризис» кытай телендә нинди иероглифлар белән языла, хәтерлисезме? Шуның икенчесе – сезнеке!

Данил СӘФӘРОВ

Спорт

«КАМАЗ»НЫ ТУКТАТТЫЛАР

Ике очрашу рәттән җиңүне кулдан ычкындырган «Рубин», ниһаять, өч очкога ия булды. Казан командасы Мәскәү өлкәсендә 2:1 исәбе белән «Велес»тан өстен чыкты. Шунысы да бар: Леонид Слуцкий футболчылары хәлиткеч тупны очрашу ахырында гына кертә алды.

Әлеге уңыштан соң «Рубин» турнир таблицасында өченче урынга күтәрелде. Беренче урында – «Алания». Владикавказ командасы сезон башыннан бирле беренчелекне бирмәгән «КАМАЗ»дан 4:2 исәбе белән өстен чыкты. Алдагы 8 очрашуда Чаллы футболчылары нибары 4 туп керттергән иде. Бу – «КАМАЗ»ның беренче җиңелүе. Чаллы командасы турнир таблицасында икенче урынга төште. «Нефтехимик» 1:2 исәбе белән «Арсенал»га оттырды.

	команда	очко
1	Алания Владикавказ	18
2	КАМАЗ	18
3	Рубин	16
4	Арсенал	16
5	Енисей	16
6	Балтика	15
7	Волгарь	15
8	Нефтехимик	14
9	Динамо	13
10	Шинник	11
11	Краснодар-2	10
12	СКА-Хабаровск	10
13	Уфа	9
14	Велес	9
15	Кубань	8
16	Родина	7
17	Акрон	6
18	Волга	4

rubin-kazan.ru

Лилия ГЫЙМАЗОВА

КУНАК АШЫ

kazan-mfmk.com

Казан халыкара мөселман киносы фестиваленең унсигезенчесе тәмам. Фильмнар бәяләнде, бүләкләр тапшырылды, кунаклар таралышты. Татарстан киносын үстерүе белән кадерле фестиваль өметләрне акладымы? Безгә кем өчен сөенергә? Кинофестивальнең йомгаклау тантанасында әнә шул сорауларга җавап эзләп карадык.

Үзебезчә…ме?

Киемеңә карап каршы алалар, дип әйтәләр бит әле. «Пирамида» каршына җәеп куелган кызыл келәмнән узучыларның да тышкы кыяфәтенә бәя биреп торды килгән халык. Дөрес, халык дигәнем, күп булса, 10–15 кеше инде. Ачылыш тантанасының да, ябылышның да бу өлешенә игътибар бермә-бер кимегән. Гәрчә «йолдызлы» кунаклар күп булачак, дисәләр дә. Аннан соң, узган ел күп кеше киемдә миллилеккә өстенлек биргән булса, быел алары да аз күренде, булганнары да кунакларыбыз иде.

Аның каравы, эчкә узуга, милли моңнар белән каршы алдылар. Йомгаклау тантанасында да Данияр Соколов җитәкчелегендәге Камал театры оркестры үзебезнең көйләрне яңгыратып торды, фестивальнең җиңүчеләрен халык җырлары астында котладылар. Сәйдә Мөхәммәтҗанова белән Илнар Шәрәфетдинов башкаруындагы «Болгар йортым – хәтер кыйбласы» җырыннан соң да алкышлар озак тынмый торды. Казан дәүләт мәдәният институты ректоры Роза Әхмәдиева да кунакларны «Туган тел»не җырлап сәламләде. Җиңүчеләргә бүләкләр алып чыгучы кызларның милли киемнән булуын да өстәсәң, фестивальнең йомгаклау тантанасында чын безнеңчә, милли өлешләр башка булмады.

Рәхмәтне казахларга әйттек

Кино тантанасының үзенә күчик. Быел чараны кино һәм театр артисткасы Гүзәл Сибгатуллина белән Россия актеры Иван Колесников алып барды. Гүзәл Сибгатуллина сөйләгән саен диярлек, кунак егет: «Какой же красивый ваш язык!» – дип сокланды. Монысы өчен рәхмәт! Татар исемнәрен дә дөрес итеп әйтсә, гел шәп буласы иде дә бит…

Иң беренче эш итеп Татарстан Премьер-министры урынбасары Васил Шәйхразыев Президентның «Кино сәнгатендә гуманизм идеяләре өчен» дигән махсус бүләген тапшырды.

– Без бу фестивальгә зур өметләр баглаган идек. Соңгы биш көн дәвамында Казан, бөтен Татарстан кино мохитендә яшәде. Һәм моның өчен барлык шартлар да тудырылган иде. Әлеге фестивальдә чит илләрдән дә катнашучыларның булуы (быел 23 илдән килделәр. – Авт.) безне бик сөендерә. Димәк, безгә ышаналар, – диде ул. – Татарстан Президентының махсус бүләге – үзенә күрә рәхмәт сүзе. Аны тапшыру һәрвакыт дулкынландыра.

Шулай итеп, быел 500 мең сум күләмендәге «рәхмәт» Россия белән Казахстанның уртак кинопроекты – «Рух» фильмына әйтелде. Сүз уңаеннан, Казахстан быел фестивальдән шактый бүләкләр белән кайтып китте. Татарстан белән берлектә төшерелгән «Тарлан» фильмы «Тамашачы мәхәббәте» номинациясендә җиңде. Жюри әгъзаларының махсус бүләкләрен дә казахлар алды.

Безгә – үзебезнеке

Гомумән алганда, быелгы фестивальне югары бәяләделәр. Фильмнар күп, яхшылары җитәрлек. Кызыксынып килеп, карап китүчеләр дә бар. Бигрәк тә Идел буе Болгар дәүләтендә ислам динен кабул итү тарихын кино итеп күрсәтүдә Татарстан кинематографистларының беренче тәҗрибәсе булган, режиссер Айназ Мөхәммәтҗанов төшергән «Ибн-Фадлан» фильмы зур кызыксыну уяткан. Ике көндә аны 1000ләп кеше карап өлгергән. Фестиваль дә әлеге документаль фильмны игътибарсыз калдырмады. Режиссерга «Тарихи әһәмияткә ия булган вакыйганы тасвирлаган өчен» дигән махсус премия тапшырдылар.

«Ибн-Фадлан» төп конкурска кертелмәгән иде. Халыкара конкурста Казахстан белән берлектә төшерелгән «Тарлан» (реж. – Юлия Захарова), «Галиябану» (реж. – Рифат Миндубаев), «Габдрахман» (реж. – Марсель Мәхмүтов), «Сосновый ключ» (реж. – Булат Минкин) фильмнары гына катнашты. «Тарлан» турында әйттек инде. Моннан тыш, «Галиябану» фильмына да Казан мэрының махсус бүләге тапшырылды. Шуның белән шул. Безгә – үзебезнеке генә. Узган елгы фестивальдә татар киносына өмет уяткан һәм Президентның махсус бүләгенә ия булган «Исәнмесез?» кебек бер фильм җитмәде…

«Иң яхшы тулы метражлы нәфис фильм» номинациясендә Иранда төшерелгән «Тихая слава» фильмы җиңүче дип табылды һәм төп призны алды. Гран-при иясен мәдәният министры Ирада Әюпова бүләкләде. 35 яшьлек Роханның язмышын бәян итүче әлеге фильмның режиссеры Нахит Хәсәнзадә «Пирамида» сәхнәсенә өч тапкыр күтәрелде. Фильм NETPAC Азия киносын үстерү челтәренең махсус бүләгенә ия булды һәм «Тулы метражлы нәфис фильмда иң яхшы хатын-кыз роле» номинациясендә җиңде.

XVIII КАЗАН ХАЛЫКАРА МӨСЕЛМАН КИНОСЫ ФЕСТИВАЛЕ ҖИҢҮЧЕЛӘРЕ:

- ✓Татарстан Президентының «Кино сәнгатендә гуманизм идеяләре өчен» махсус бүләге – «Рух» (Россия – Казахстан, реж. – Михаил Плиско);
- ✓«Тамашачы мәхәббәте» бүләге – «Тарлан» (Татарстан – Казахстан, реж. – Юлия Захарова);
- ✓Жюри әгъзаларының махсус бүләге – «Мукагали» (Казахстан, реж. – Болат Калымбетов);
- ✓Казан мэрының махсус бүләге – «Галиябану» (Татарстан, реж. – Рифат Миндубаев);
- ✓«Ислам дөньясында мәдәниятләр диалогы өчен» – «Сагынбай Манасчы» (Кыргызстан, реж. – Эрнест Абдыжапаров);
- ✓«Тулы метражлы нәфис фильмда иң яхшы ир-ат роле» – «Газета» фильмы геройлары Сарат Коталавала һәм Кумара Тиримадура (Шри-Ланка, реж. – Сарат Коталавала һәм Кумара Тиримадура);
- ✓«Тулы метражлы нәфис фильмда иң яхшы хатын-кыз роле» – «Тихая слава» фильмы героинясы Джила Шахи (Иран, реж. – Нахит Хәсәнзадә);
- ✓«Иң яхшы тулы метражлы нәфис фильм сценарие» – «Приключения маленького Бахи» (Россия, сценарий авторы – Анна Вейлерт);
- ✓«Тулы метражлы фильмда иң яхшы оператор эше» – Томмасо Фиорилли («Гнев», Россия – Ливан – Германия);
- ✓«Тулы метражлы иң яхшы нәфис фильм режиссеры» – Мәһди Әхмәд Али («Улица Талаата Харба», Мисыр);
- ✓«Иң яхшы кыска метражлы документаль фильм» – «Жизнь» (Төркия, реж. – Мөхәммәд Әмин Демирал);
- ✓«Иң яхшы кыска метражлы нәфис фильм» – «Младший брат ангелов» (Таҗикстан, реж. – Умедшо Мирзоширинов);
- ✓«Иң яхшы тулы метражлы документаль фильм» – «Иванова Лествица» (Франция – Россия, реж. – Николай Бем);
- ✓«Иң яхшы милли фильм» – «Без – 41 нче ел балалары» (реж. – Әмир Галиәскәров);
- ✓«Иң яхшы документаль милли фильм» – «Посланник» (реж. – Зөфәр Хәйруллин).

Илдар Мөхәммәтҗанов

ХАЛЫК СЫНАМЫШЛАРЫ

- ➢ Август яңгырсыз килсә, җылы һәм коры көзгә.
- ➢ Сентябрь җылы һәм коры булган саен, кыш соңрак килә.
- ➢ Сентябрьдә кырмыскалар үлән өстендә чабышса, кар тирән булып ятар. Кырмыска оялары биек булса, салкын кыш көтәргә. Быел ояларның биеклеге уртача.
- ➢ Чикләвек күп, гөмбә аз булса, карлы һәм салкын кыш көтелә.
- ➢ Икмәк уңса, кыш салкын килә.

ӘБИЛӘР ЧУАГЫМЫ БУ?

Фараз

Кызык инде без. Башта август ахырындагы эссегә түзә алмыйча, тизрәк кояшның сүрелүен, яңгырлар явуын көттек. Сентябрь башында көннәр суытып җибәргән иде, җылыны сагына ук башладык. Ни генә булмасын, синоптиклар озын, җылы көз вәгъдә итә. Бәрәңгеләрне казып бетерүгә, күктә кояш елмайды: әбиләр чуагымы бу?

– Әбиләр чуагы яңгырлы салкын көннәрдән соң башлана. Сентябрь башы нәкъ шундый булды. Скандинавия антициклоны якынлашу сәбәпле, атна башында безгә кояшлы, бераз салкынчарак һава торышы кирә. Тик ул эссе алып килмәячәк. Мондый көннәр күпме дәвам итәр? Хәзергә көндез 16–18 градус җылы, кичләрен салкынчарак булачак. Тик Атлантика циклоны явым-төшемнәр алып килер дигән шик тә бар, – диде безгә КФУның метеорология, климатология һәм атмосфера экологиясе кафедрасы мөдире Юрий Переведенцев.

Белгеч әйтүенчә, гадәттә, әбиләр чуагы сентябрь урталарында башлана. Ул ике көннән алып ике атнага кадәр сузыла ала, арада өзеклек тә булырга мөмкин. Бу чорда 20–25 градуска кадәр җылы һава торышы саклана. «Бу атнада берничә көн дәвамында антициклон йогынтысында кыска гына әбиләр чуагы булып алыр. Бәлкем, башка өлеше сентябрь ахырында килер. Моны сезгә беркем дә төгәл генә әйтмәячәк», – диде Юрий Переведенцев.

Сарман районының Иске Минзәләбаш авылында яшәүче халык синоптигы Илдар Әшрәфуллинның фикерен дә белештек. Ул – элеккеге колхоз рәисе, утыз ел буе һава торышын күзәтеп, явым-төшемнәргә бәйле мәгълүматларны теркәп бара. Фаразларны күбрәк халык сынамышларыннан да чыгып әйтә ул. Аның әйтүенчә, быел көз озын булачак. Ни өчен дигәндә, сентябрьдә яшен яшьнәве дә, 12 июльдән соң күке кычкыруы да, торналарның биектән ашыкмыйча узуы да, черкиләрнең күп булуы да – озын көзгә ишарә. Яңгыры да булачак. Миләш күп булганда, көз яңгырлы киләчәк, диләр. Быел миләштән уңдык.

– Әбиләр чуагы, гадәттә, 14 сентябрьдән 24енә кадәр була. Быел да башы шулай булыр, әмма аның дәвамы октябрь аенда да көтелә әле. Быел ел фасыллары болай да 20 көнгә соңарып килә, – диде Илдар Әшрәфуллин.

Сәрия МИФТАХОВА

Баш мөхәррир –
САБИРОВА Гөлнара Ильяс кызы

Газетаны оештыручылар:
ТАТАРСТАН ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ, МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ, РЕДАКЦИЯНЕҢ ХЕЗМӘТ КОЛЛЕКТИВЫ

Газета Татарстан Республикасы Информация һәм матбугат министрлыгында 1995 елның 21 июнендә теркәлгән.

Теркәү таныклыгының номеры – 430.
Газета матбугат чараларының үзәк каталогына кертелгән.

Тираж – 6708 данә
Гомуми тираж – 15890 данә

Газетага сертификат бирелде Заказ 333

РЕДАКЦИЯ ҺӘМ НӘШЕР АДРЕСЫ
420097, Казан, Академия ур., 2 й.
«Ватаным Татарстан» газетасы редакциясе.
www.vatantat.ru
info@vatantat.ru, vatantat@list.ru, vtreklama@mail.ru
89179270040
Индекс П2409 (гадәти сан – атнага дүрт тапкыр чыга)
П2448 (гадәти сан, пенсионерлар өчен)
П2449 (гадәти сан, оешмалар өчен)
П2435 (җомга саны)

ТЕЛЕФОННАР
222-09-70 – кабул итү бүлмәсе
222-09-67 – баш мөхәррирнең беренче урынбасары
222-09-73, 222-09-69, 222-09-65 – баш мөхәррир урынбасарлары
222-09-68 – авыл хуҗалыгы, фән һәм мәгариф
222-09-67 – дин, сәламәтлек
222-09-64 – әдәбият, сайт
222-09-66 – сәясәт, тәрҗемә, оператор, хатлар һәм социаль мәсьәләләр
222-09-65 – реклама бүлеге
222-09-72 – бухгалтерия
222-09-73 – компьютер үзәге
221-18-99 – газета килмәсә яки соңарып килсә

Оригинал макет **Jahat™** программалар пакеты ярдәмендә әзерләнде. Мәкалә авторларының фикерләре редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин. Хатлар, кульязмалар, рәсемнәр рецензияләнми һәм кире кайтарылмый.
R тамгасы куелган язмалар реклама буларак тәкъдим ителә.
N тамгасы куелган язмалар килешү нигезендә басыла.

Күчереп бастыру өчен редакциядән язмача рөхсәт алу шарт.
График буенча бу санга 20 сәгатьтә кул куелырга тиеш.
Кул куелды – 20 сәгатьтә.

Ваклап сату бәясе килешү буенча.

Газета «ТАТМЕДИА» АҖ филиалы «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылып чыкты **(420066, Казан шәһәре, Декабристлар ур., 2й.).**

16+